РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
НИЖНЕКАМСКИЙ
ГОРОДСКОЙ СОВЕТ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТҮБӘН КАМА
ШӘҺӘР СОВЕТЫ

пр. Строителей, д. 12, г. Нижнекамск, 423570

Төзүчеләр пр., 12 нче йорт, Түбән Кама шәһәре, 423570

Тел./факс: (8555) 42-42-66. E-mail: Gorsovet.Nk@tatar.ru

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

2022 елның 15 сентябре № 37

Түбән Кама шәһәр Советының «Түбән Кама муниципаль районы Түбән Кама шәһәре муниципаль берәмлегенең шәһәр төзелешен проектлауның җирле нормативларын раслау турында» 2017 елның 15 сентябрендәге 24 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Янгын куркынычсызлыгы таләпләре турында техник регламент» Федераль законына үзгәрешләр кертү хакында» 2022 елның 14 июлендәге 276-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Түбән Кама шәһәр Советы

КАРАР БИРӘ:

1. Түбән Кама шәһәр Советының «Түбән Кама муниципаль районы Түбән Кама шәһәре муниципаль берәмлегенең шәһәр төзелешен проектлауның җирле нормативларын раслау турында» 2017 елның 15 сентябрендәге 24 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә

7.3.16 пунктында «җирлекләр һәм шәһәр округлары» сүзен «торак пунктлар» сүзләренә алмаштырырга;

7.3.18 пунктында «гомуми челтәрдәге тимер юллар» сүзләрен «тимер юллар» сүзләренә алмаштырырга, «гомуми челтәрдәге тимер юлында» сүзләрен «тимер юллар» сүзләренә алмаштырырга;

7.3.22 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Янгынга каршы аралык янгынның урманнардан биналарга һәм корылмаларга кадәр таралмавын тәэмин итәргә тиеш.»;

7.3.23 пунктында «урманчылыкларда» сүзләрен төшереп калдырырга;

7.3.37 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7.3.37. Янгынга каршы су белән тәэмин итү чыганаклары буларак, үзәкләштерелгән һәм (яки) үзәкләштерелмәгән су белән тәэмин итү системалары, су объектлары, шулай ук янгын сусаклагычлары файдаланылырга мөмкин.»;

7.3.38 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7.3.38. Янгынга каршы су белән тәэмин итүне, су белән тәэмин итү системалары җиһазларын, сууткәргеч челтәрләрен, ясалма сулыкларны һәм янгын сусаклагычларын тәэмин итү зарурлыгы, янгынга каршы тору өчен су объектларыннан файдалану «Янгын куркынычсызлыгы таләпләре турында техник регламент» 2008 елның 22 июлендәге 123-ФЗ номерлы Федераль закон белән, ә аларны урнаштыруга таләпләр янгын куркынычсызлыгы буенча норматив документлар белән билгеләнә. Су объектларының һәм янгын сусаклагычларының су запасы, янгын сүндерү вакытын исәпкә алып, биналар һәм корылмаларның янгын сүндерү өчен исәпләнгән чыгымнарын тәэмин итәргә тиеш.»;

7.3.40 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7.3.40. Торак пунктлар территорияләрендә янгын сүндерү депосы биналарын шәһәр торак пунктларында чакыру урынына беренче бүлекчәнең килеп җитү вакыты 10 минуттан, авыл торак пункитларында 20 минуттан артмаска тиеш дигән шарттан чыгып урнаштырырга кирәк.»;

4.7.51, 4.7.52, 7.3.2 пунктларын үз көчен югалткан дип танырга.

2. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Түбән Кама шәһәр Советының шәһәр инфраструктурасын үстерү буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Түбән Кама шәһәре Мэры
вазыйфаларын башкаручы,
Мэр урынбасары

М.В. Камелина